РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел./факс +7(84396) 2-59-00, email: cheremshan@tatar.ru, http://cheremshan.tatarstan.ru

«_29_» _октябрь__ 2020 ел №_9__

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Советы
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының 2018 елның 6 мартындагы 142 номерлы «Татарстан Республикасы «Чирмешән муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында», 2020 елның 31 июлендәге 268-ФЗ номерлы «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законнар, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» Татарстан Республикасы законы, «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының 2018 елның 6 мартындагы 142 номерлы карары белән (муниципаль район Советының 2018 елның 24 апрелендәге 156 номерлы, 2018 елның 28 августындагы 181 номерлы, 2019 елның 12 апрелендәге 212 номерлы, 2020 елның 26 июнендәге 281 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) расланган Татарстан Республикасы «Чирмешән муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы «Чирмешән муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 12 апрелендәге 212 номерлы карарының 3.6.1 пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга.

1.2. 4.1.3 пунктында:

- 4 пунктчаны бәян итәргә «хезмәт кенәгәсен һәм (яки) хезмәт эшчәнлеге турында законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән белешмәләр, хезмәт килешүе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш»;

- 6 пунктчаны бәян итәргә: «хезмәт килешүе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш, индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслаучы документ».

1.3. 8.1 пунктның 4 пунктчасын бәян итәргә: «муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт кенәгәләрен алып бару (булган очракта), муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан муниципаль хезмәт узган чорда хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар формалаштыру һәм әлеге белешмәләрне мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (персональләштерелгән) исәпкә алу турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә, Россия Федерациясе Пенсия фондының мәгълүмат ресурсларында саклау өчен бирү».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чирмешән муниципаль районы Советының җирле үзидарә, Совет регламенты, хокук тәртибе, экология һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Муниципаль район
Башлыгы, Совет рәисе Ф.М. Дәүләтшин